Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2011, 18 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә "язма рәвештә" сүзләреннән соң "яисә электрон документ рәвешендә" сүзләрен өстәргә;

2) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документлар бирүне, мондый документлар "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән документлар исемлегенә кертелгән очраклардан тыш, таләп итү рөхсәт ителми.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 13 декабре
№ 102-ТРЗ